**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карары**

Чубар-Абдулавылы №184 Чубар-Абдул 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул_авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2013 елның 7 октябрь 78 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен тозекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (18.03.2014 №98, 16.08..2014 №116, 25.08.2017 №65, 06.03..2019 №130 номерлы карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Чубар-Абдул_авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул_авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2013 елның 7 октябрь 78 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен тозекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (18.03.2014 №98, 16.08..2014 №116, 25.08.2017 №65, 06.03..2019 №130 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2. пунктның өченче абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.3. пунктның унынчы абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2.7. пунктта «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 2.10.3 – 2.11.2, 2.11.4 пунктларда «каты көнкүреш калдыклары»

сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә, «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.5. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.7 пункт белән тулыландырырга:

«2.11.7. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Ә. Фәтхетдинов